**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1022**
**16.02.2023**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Күмү һәм җирләү эшләре турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясының 3 өлеше, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешнең 23 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2023 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» 2023 елның 30 гыйнварындагы 119 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эшләре турында» Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче, 2 нче кушымталарда каралганча 7 793,48 сум күләмендә расларга.

2. 2022 елның 25 февралендә «Челнинские известия» газетасының 13 нче санында бастырып чыгарылган «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 2022 елның 18 февралендәге 750 номерлы Башкарма комитет карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы И.Н. Гайнуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 16 февралендәге
1022 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә
җирләү буенча гарантияләнгән
хезмәтләр исемлегенә бәяләр
(якын туганнары, ире (хатыны) булган очракта)

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәтләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китереп бирү | 1 800,00 |
| 3. Үлгән кешене (мәетне) зиратка илтү | 1 800,00 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4 193,48 |
| Барлыгы | 7 793,48 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2023 елның 16 февралендәге
1022 номерлы карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә
җирләү буенча гарантияләнгән
хезмәтләр исемлегенә бәяләр
(якын туганнары, законлы вәкиле булмаган очракта)

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәтләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Мәетне төрү | 300,00 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китереп бирү | 1 500,00 |
| 4. Үлгән кешене (мәетне) зиратка илтү | 1 800,00 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4 193,48 |
| Барлыгы | 7 793,48 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева